| | | |
|---|---|---|
| | - элегрәк төзелгән аренда килешүләре буенча дәүләт мөлкәтен арендалаган өчен Татарстан Республикасы бюджеты каршында бурычлары булу (казна учреждениеләре өчен);<br>- килештерү йомгаклары буенча төзелә торган дәүләт мөлкәтен арендалау килешүләрен, элегрәк төзелгән килешүләргә өстәмә килешүләрне (үзгәрешләр кертү турында, вакытыннан алда өзү турында), аренда килешүенең гамәлдә булу срогы беткәч, арендаторның аренда бирүчегә арендаланучы мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын тапшырмау (үз вакытында тапшырмау);<br>- элегрәк төзелгән аренда килешүләрен Министрлык белән килештермичә озайту;<br>- аренда бирүченең аренда килешүләре буенча башка йөкләмәләрен бозуы.<br>4. Сатулашу уздыруның монополиягә каршы законнар белән билгеләнгән зарурлыгы (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза тапшырганда).<br>5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүчене гамәлгә куючы яки Министрлык тарафыннан, билгеләнгән тәртиптә, мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан карар кабул ителү.<br>6. Законлы көченә кергән әлеге мөлкәт белән эш | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан суд карары.<br>7. Татарстан Республикасы мөлкәтен арендалау кыйммәтен бәяләү турындагы тапшырылган отчетның бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законына туры килмәве.<br>8. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе тапшырган мәгълүматлар нигезендә, мөрәҗәгать итүченең арендага бирүгә тәкъдим ителә торган күчемсез мөлкәткә хокуклары булмау.<br>9. Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм реестрында мөрәҗәгать итүчене (дәүләт мөлкәтен сатулашу булдырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендаторны) юкка чыгару турында яки аның эшчәнлеген туктатып тору турында карар булу, яисә мөрәҗәгать итүче (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендатор) турында мәгълүматлар булмау.<br>10. Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрында күздә тотылган арендатор турында мәгълүматлар булмау (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына медицина оешмаларына арендага биргәндә). | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турындагы запрослар

3.4.2. Ведомоствоара арадашлык органнары белгечләре ведомоствоара электрон арадашлык системасы аша кергән, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган белешмәләрне (документлар) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, соралган белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында Министрлык карары яисә Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында хат әзерләү

3.5.1. Гариза бирүченең бәяләү турында отчетына экспертиза ясау өчен Бүлек белгече Бүлек башлагы имзасы белән бәяләү бүлегенә тиешле хезмәт язуы әзерли.

Бу пункт билгели торган процедура Бүлек белгече гаризаны алганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән отчетка экспертиза ясау турында бәяләү бүлегенә хезмәт язуы.

3.5.2. Бәяләү бүлеге белгече бәяләү турында отчетка экспертиза ясый, бәяләү турында отчетның бәяләү эшчәнлеге турында законнарга туры килүе яки килмәве һәм аны мөлкәтне арендага бирүне килештергәндә куллану мөмкинлеге турында хезмәт язуы (алга таба – бәяләү бүлегенең хезмәт язуы) проектын әзерли һәм аны килештерү өчен бәяләү бүлеге мөдиренә юллый.

Бу пункт билгели торган процедура Бүлеккә карау өчен бәяләү турында отчет беркетелгән хезмәт язуы кергән вакыттан соң дүрт эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү бүлегенең хезмәт язуы проекты.

3.5.3. Бәяләү бүлеге мөдире бәяләү бүлегенең хезмәт хезмәт язуы проектын килештерә һәм бәяләү бүлеге белгеченә тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура хезмәт язуы проекты имзалау өчен бәяләү бүлегенә кергәннән соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләү бүлегенең килештерелгән хезмәт язуы.

3.5.4. Бәяләү бүлеге белгече бүлек мөдире белән килештерелгән бәяләү бүлегенең хезмәт язуын имзалау өчен министр урынбасарына бирә.

Бәяләү бүлегенең хезмәт язуына министр урынбасары кул куя һәм бәяләү бүлегендә регистрацияләнгәннән соң бәяләү бүлеге белгече Бүлек белгеченә юллый.

Бу пункт билгели торган процедура имзалау өчен бәяләү бүлегенең хезмәт язуы кергәннән соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министр урынбасары кул куйган һәм Бүлеккә юлланган бәяләү бүлегенең хезмәт язуы.

3.5.5. Бүлек белгече бәяләү бүлегенең хезмәт язуы һәм ведомоствоара арадашлык юлы белән кергән белешмәләр нигезендә (күчемсез мөлкәтне арендага бирүне килештергәндә) яки гариза бирүчедән кергән документлар нигезендә (күчемле милек мөлкәтен арендага бирүне килештергәндә) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасы мөлкәтен арендага тапшыруны килештерүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

килештерү турында Министрлык карары проектын яки баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән баш тарту турында хат проекты әзерли;

килештерү турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проекты килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, Татарстан Республикасы мөлкәтен арендага тапшыруны килештерүдән баш тартыла:

1) гариза бирүче тапшырган документларда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат булуы;

2) Хокук билгеләүче документларда гариза бирүче оператив идарәнең яисә мөлкәт белән хуҗалык итүченең бәхәссез хокукы факты күренми;

3) Моннан алдагы аренда мөнәсәбәтләрендә гариза бирүченең үз бурычларын тиешенчә үтәмәве:

- элегрәк төзелгән аренда килешүләре буенча дәүләт мөлкәтен арендалаган өчен Татарстан Республикасы бюджеты каршында бурычлары булу (казна учреждениеләре өчен);

- килештерү нәтиҗәләре буенча төзелә торган дәүләт мөлкәтен арендалау килешүләрен, элегрәк төзелгән килешүләргә өстәмә килешүләрне (үзгәрешләр кертү турында, вакытыннан алда өзү турында), аренда килешүенең гамәлдә булу срогы беткәч, арендаторның аренда бирүчегә арендаланучы мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын тапшырмау (үз вакытында тапшырмау);

- элегрәк төзелгән аренда килешүләрен Министрлык белән килештермичә озайту;

- аренда бирүченең аренда килешүләре буенча башка йөкләмәләрен бозуы.

4. Сатулашу уздыруның монополиягә каршы законнар белән билгеләнгән зарурлыгы (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза тапшырганда).

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүчене гамәлгә куючы яки Министрлык тарафыннан, билгеләнгән тәртиптә, мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан карар кабул ителү.

6. Законлы көченә кергән әлеге мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан суд карары.

7. Татарстан Республикасы мөлкәтен арендалау кыйммәтен бәяләү турындагы тапшырылган отчетның бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законына туры килмәве.

8. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе тапшырган мәгълүматлар нигезендә, мөрәҗәгать итүченең арендага бирүгә тәкъдим ителә торган күчемсез мөлкәткә хокуклары булмау.

9. Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм реестрында мөрәҗәгать итүчене (дәүләт мөлкәтен сатулашу булдырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендаторны) юкка чыгару турында яки аның эшчәнлеген туктатып тору турында карар булу, яисә мөрәҗәгать итүче (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендатор) турында мәгълүматлар булмау.

10. Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрында күздә тотылган арендатор турында мәгълүматлар булмау (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына медицина оешмаларына арендага биргәндә).

Бу пункт билгели торган процедуралар запросларга җаваплар алынган һәм бәяләү турында отчетка экспертиза нәтиҗәләре белән бәяләү бүлегенең хезмәт язуы кергәннән соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хат яки килештерү турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.6. Бүлек мөдире килештерү турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты карый, килештерә һәм килештерү турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын Бүлек белгеченә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире килештергән килештерү турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.7. Бүлек белгече Бүлек мөдире белән килештерелгән килештерү турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

3.5.6, 3.5.7 пунктлар билгели торган процедуралар алдагы процедуралардан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән, имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган килештерү турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.8. Министрның беренче урынбасары килештерү турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын имзалый һәм

Татарстан Татарстан Республикасы
милкендә булган мөлкәтне арендага
бирүне килештерү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздыру юлы белән арендага бирүне килештерүгә**
**ГАРИЗА**

Гариза бирүче: ______________________________________________
( Оешма атамасы)

______________________________________________йөзеннән
(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме)

**Мөлкәтне (объектны) ____________ срокка арендага бирүне килештерүегезне үтенәм**
атамасы
______________________________________________
(беркетелгән исемлек нигезендәге бина, җиһаз)

Бина төре ______________________________________________
(административ, производство, склад, башка төр)

арендага бирелә торган объектның максатчан билгеләнеше ———————————

| | | |
|---|---|---|
| **Мөлкәтнең (бүлмәнең) адресы:**<br>42_______ , _____________ел<br>Район ____________________<br>____________________урамы<br>____________________йорт | **Бүлмәнең тасвирламасы:**<br>Мәйданы: _______________ $м^2$<br>Подвалда _______________ ,<br>цокольда<br>____________________,<br>___________________ катта,<br>__________ катлы бина.<br>Аерым керү урыны (әйе/юк) | **Бинада**<br>(әйе/юк):<br>Электр уты__________<br>Үзәкләштерелгән җылыту<br>_______________<br>Су ________<br>Канализация __________ |
| **ТИБ техник паспорты**<br>**әйе / юк**<br>**Төзелгән датасы:** | Җир төзү документлары: җиргә дәүләт акты<br>әйе / юк, дата _______________________<br>**Кадастр өземтәсе: әйе / юк ; дата**_______________<br>**башкалар** ______________________________<br>**Дата** ____________________ | |

**Тапшырылган мәгълүматларны раслыйм:**

**Гариза бирүченең имзасы:** ______________________ **м.п. Дата:** ________________

Оешманың тулы атамасы ______________________________________________
______________________________________________ ОКПО ____________________
______________________________________________ нигезендә гамәл кылучы
җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме____________________
____________________________________ ,
Оешманың юридик адресы: 42____________ , ел. ______________________________

Баланста торучы бүлмәләрнең гомуми мәйданы кв. м ______________________________
Төзелгән килешүләр буенча арендага бирелгән мәйдан, кв. м ______________________
Оешманың арендатор белән эшләү буенча вәкаләтле заты
____________________________________телефон____________________________

Татарстан Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча арендага бирүне килештерүгә**
**ГАРИЗА**

Гариза бирүче: ________________________________________________________________
( Оешма атамасы)

__________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Мөлкәтне (объектны) ____________ срокка арендага бирүне килештерүегезне үтенәм**

атамасы ________________________________________________________________
(кушымта итеп бирелүче исемлеккә туры килә торган бүлмә, җиһаз)

бинаның тибы ______________________________________________________
(административ, җитештерү, склад, башкалар)

бирелә торган объектның максатчан билгеләнеше_________________________________
__________________________________________________________________________

тәкъдим ителә торган арендатор (атамасы, ИНН) ________________________________

| **Мөлкәтнең (бүлмәнең) адресы:**<br>42_______ , _____________ел<br>Район _____________________<br>_____________________урамы<br>_____________________йорт | **Бүлмәнең тасвирламасы:**<br>Мәйданы: _______________ м$^2$<br>Подвалда _______________ ,<br>цокольда<br>____________________,<br>___________________ катта,<br>__________ катлы бина.<br>Аерым керү урыны (әйе/юк) | **Бинада**<br>(әйе/юк):<br>Электр уты__________<br>Үзәкләштерелгән җылыту<br>_____________<br>Су ________<br>Канализация __________ |
|---|---|---|

| **ТИБ техник паспорты**<br>**әйе / юк**<br>**Датасына төзелгән:** | Җир төзү документлары: җиргә дәүләт акты<br>әйе / юк, дата _______________________________<br>**Кадастр өземтәсе: әйе / юк ; дата**_______________<br>**Башкалар**_________________________________________<br>**Дата** _____________________ |
|---|---|

**Тапшырылган мәгълүматларны раслыйм:**

**Гариза бирүченең имзасы:** ________________________ **м.п. Дата:** ________________

Оешманың тулы атамасы ____________________________________________________

_____________________________________________ ОКПО ______________________________
____________________________________________ нигезендә гамәл кылучы
җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме_______________________________
_______________________________________ ,
Оешманың юридик адресы: 42____________ , ел. ________________________________

Район ____________________, ____________________________урамы, ☎

